

# КАК ЛИСА КУРЯТНИК СТРОИЛА

## ТАТАРСКИЕ СКАЗКИ, ЛУКАВЫЕ И ВЕСЕЛЫЕ

- *практические задания*
- *ответы для самопроверки*
- *пересказ на русском языке*
- *аудиоприложение*

# АБЗАР ЯСАУЧЫ ТӨЛКЕ

## ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ, ХӘЙЛӘКӘР ҺӘМ ШАЯН

ТАТАРЧА

БИРЕМЛЕ УКУ. Чтение с упражнениями

# КАК ЛИСА КУРЯТНИК СТРОИЛА

## Татарские сказки, лукавые и веселые

# АБЗАР ЯСАУЧЫ ТӨЛКЕ

## ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ, ХӘЙЛӘКӘР ҺӘМ ШАЯН

БАЗОВЫЙ УРОВЕНЬ

БАЗА ДӘРӘҖӘСЕ


Составление, пересказ и упражнения

**Л. Г. Латфуллиной, Р. Р. Муртазиной**



КАРО

Санкт-Петербург

УДК 811.512.145
ББК 81.632.3
К16

ПРИОБРЕТАЙТЕ
·АУДИО·
ПРИЛОЖЕНИЕ
KARO.SPB.RU

*Аудиоприложение приобретается отдельно
на сайте karo.spb.ru или по QR-коду на обложке книги*

**К16** **Как лиса курятник строила. Татарские сказки, лукавые и веселые** / Составление, пересказ, упражнения Л. Г. Латфуллиной, Р. Р. Муртазиной. — Санкт-Петербург : КАРО, 2026. — 128 с. : ил. — (Чтение с упражнениями).

ISBN 978-5-9925-2091-0.

В сборник вошли 15 татарских народных сказок. Для удобства читателя каждая сказка сопровождается пересказом на русском языке, а также упражнениями на знание базовой и более сложной лексики, отработку распространенных грамматических конструкций, понимание и употребление устойчивых выражений.

Для тренировки восприятия устной речи на татарском языке каждая сказка озвучена и представлена в аудиоприложении к сборнику.

Книга предназначена для тех, кто изучает татарский язык самостоятельно или с преподавателем, а также интересуется татарской культурой в целом.

Рекомендуемый уровень владения татарским языком: А2 и выше.

УДК 811.512.145
ББК 81.632.3

**ISBN 978-5-9925-2091-0**

© КАРО, 2026
Все права защищены

## ОТ СОСТАВИТЕЛЕЙ

Дорогие друзья!

У вас в руках сборник татарских народных сказок.

Сказка — один из самых популярных фольклорных жанров. По-татарски она называется *әкия́т*. Некоторые люди старшего поколения сказку называют *хикәя́т* (рассказ). Оба эти слова происходят от арабского понятия *«хикаят»* (حكاية), которое обозначает не имеющее конкретного автора, то есть народное повествование, часто с фантазийным содержанием, изредка в стихотворной форме. А у сибирских татар сказка носит название *йома́к*, то есть загадка. Сказка в представлении татарского народа связана с чудесными, загадочными и таинственными, но при этом близкими к жизни народа историями, в которых неразрывно слиты правда и волшебство жизни.

Каждая сказка в этом сборнике — не только захватывающая история и новые слова и выражения для пополнения лексического запаса, но и возможность для читателя ближе познакомиться с богатым духовным наследием татарского народа: его историей и культурой, традициями и обычаями.

Сборник состоит из пятнадцати сказок, которые можно отнести к таким жанровым разновидностям, как: *бытовые сказки, волшебные сказки и сказки о животных*.

О всепобеждающей силе любви, доброте, о душевной красоте и стойкости человека, его готовности на любые испытания ради родных и любимых людей поведано в *бытовых* сказках *«Васыять»* («Завещание»), *«Зирәк карт»* («Мудрый старик»), *«Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми»* («С ремеслом

не пропадешь, без ремесла не проживешь»), *«Өч сорау»* («Три вопроса») *«Туры сөйләгән котылган, ялганлаган тотылган»* («Правду сказал — спасся, солгал — попался»).

В центре внимания *волшебных сказок* — образ идеального героя, богатыря. Это сказки *«Акыл белән Бәхет»* («Мудрость и счастье»), *«Башмак»* («Башмак»), *«Камыр Батыр»* («Камыр Батыр»), *«Өч кыз»* («Три дочери»), *«Өч угыл»* («Три сына»). Само русское слово «богатырь», скорее всего, происходит от тюркского «батыр», что означает «герой, смелый человек, храбрец». Первое значение этого слова связано именно с храбростью и доблестью, а уже позже к нему присоединится представление о «богатырской силе» и «богатырском здоровье». Это понятие обогатило не только образный строй русских былин и сказок, но и сам русский язык, а также многие другие языки — хинди, монгольский, бурятский, иранский.

В сказках высмеивают жадных, корыстных людей, обманщиков, лентяев и трусов, с любовью и уважением изображают смелых, бескорыстных и честных людей. Им стараются помочь и звери, и птицы — вся природа.

Основные герои сказок *о животных* — птицы и звери, такие как хитрая и расчетливая Лиса, сильный и наивный Медведь, кровожадный хищник и при этом верный помощник Волк, трусливый и безобидный Заяц, храбрый и решительный Петух и другие. Об этих героях вы прочитаете в сказках: *«Абзар ясаучы төлке»* («Как лиса курятник строила»), *«Аю, Бабай, Төлке»* («Дед, Медведь и Лиса»), *«Батыр әтәч»* («Храбрый петух»), *«Куркак юлдаш»* («Трусливый попутчик»), *«Төлке белән Бүре»* («Лиса и Волк»).

Очень часто герои сказок характеризуются и раскрываются народными пословицами и поговорками. Например: *«Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми»* («С ремеслом не пропадешь, без ремесла не проживешь»), *«Исәпле көн тиз үтә»* («Считаные дни проходят быстро»), *«Эш кешесенең эштә, юл кешесенең юлда булуы яхшы»* («Хорошо, когда работник — на работе,

а путник — в пути»), *«Куркак кеше белән юлга чыкма»* («Не отправляйся в путь с трусом») и другие.

В татарских сказках, как и в сказках других народов, прославляются доброта, честность, трудолюбие и находчивость — живость ума и способность принимать нестандартные решения.

Для того чтобы сказки были интересны, текст легко запоминался, а грамматика татарского языка хорошо усваивалась, сборник построен следующим образом:

- приводится текст сказки на татарском языке;
- к каждой сказке предлагаются упражнения: фонетические, лексические и грамматические задания;
- краткий пересказ на русском языке поможет проверить, правильно ли был понят смысл сказки;
- определение набора новых слов, словосочетаний, крылатых выражений, пословиц и поговорок даст возможность расширить словарный запас;
- ключи к упражнениям в конце сборника позволят проверить правильность выполнения заданий.

Эта книга предназначена для читателей, владеющих татарским языком на базовом уровне. Сказки можно читать самостоятельно, с родителями или под руководством преподавателя.

Надеемся, что татарские народные сказки, раскрывающие богатство души татарского народа, его взгляды на жизнь, высокие моральные качества, не оставят вас равнодушными.

Приятного чтения вам, друзья!

Составители сборника:
Ландыш Гиниятовна Латфуллина,
Руфия Рауфовна Муртазина

*Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк үрәтник, карга плотник булганда, атлар диңгездә йөзгәндә, балыклар җирдә йөргәндә, кешеләр аяк белән күктә очканда, яшәгән, ди, булган ди… Сөйләгәнне ишеткән идем, үзем күрмәдем…*

Татар халык әкиятләре шулай башланып китә…

*В давние времена, когда козы были командирами, сороки — сотниками, утки — урядниками, вороны — плотниками, когда лошади плавали в море, рыбы ходили по земле, а люди летали по небу, говорят, жили, сказывают, были… Я сам не видел, только слышал, как рассказывали…*

Так начинаются татарские народные сказки…

# Васыять

Борын заманда булган икән, ди, бер карт. Аның булган, ди, өч улы.

Үләр алдыннан карт иң элек үзенең олы улын чакырып алып әйткән:

— Син, улым, — дигән, — хәлеңнән килсә, авыл саен йорт сал, — дигән.

Шуннан соң уртанчы улын чакырып алган:

— Син, улым, — дигән аңа, — гел тәмле аш кына ашап тор, — дигән.

Карт кече улына әйткән:

— Син, — дигән, — ешрак өйләнергә кара, — дигән.

Ярар. Карт үлеп китә. Аталары үлгәч, уллары: «Әти әйткән васыятьне ничек кенә итеп үтәрбез икән?» — дип, баш ватып йөри башлыйлар.

Олы улы: «Ничек кенә итеп авыл саен йорт салдырырмын икән?» — дип, баш вата, уртанчы улы дөньяда нинди тәмле ризык бар, шуны эзләргә дип чыгып китә, ә кече уллары ешрак өйләнү турында хыялланып йөри башлый.

Көннәрдән бер көнне боларга бер карт килеп керә. Исәнлек-саулык сораша, тормышлары белән кызыксына бу боларның.

— Тормыш бик шәптән түгел әле, бабай, — ди олы уллары. — Менә әти үлгән вакытта: «Авыл саен йорт

салдыр», — дип әйтеп киткән иде, әле әтинең васыятен үти алганым юк, — ди.

Уртанчысы әйтә:

— Миңа әти: «Тәмле аш кына ашап тор», — дип әйткән иде, — ди.

Иң кечеләре дә сүзгә катнашып әйтә:

— Әти миңа: «Ешрак өйләнергә кара, улым», — дип әйткән иде. Мин дә әти васыятен үтәргә тырышып карыйм да, барып чыкмый, — ди.

Карт боларның сүзләрен тыңлап-тыңлап тора да болай ди:

— Әй, улларым, сез атагызның васыятен ялгыш аңлагансыз икән, — ди. — Ул сезгә менә болай дип әйткән, — ди, — «авыл саен йорт сал» диюе «авыл саен дус-иш булдыр, дөньяда дуслар белән яшәве җиңелрәк була» дип әйтүе булган; «тәмле ашлар ашап кына яшә» диюе «эшләп ашасаң, кара икмәк тә бик тәмле булыр» дип әйтүе аның; «ешрак өйлән» дип әйтүе, «эш артыннан йөреп, хатыныңны сагыныбрак кайтсаң, көн дә өйләнгән кебек булыр» дип әйтүе ул, — ди. — Атагыз сезне эшләп көн итәргә өндәгән», — ди.

Шулай дип әйтә дә карт чыгып китә.

Шуннан соң болар әтиләренең васыятьләрен ул кушканча үти башлыйлар.

## УПРАЖНЕНИЯ

**1 Переведите следующие слова и выражения с русского языка на татарский.**

| | |
|---|---|
| завещание | есть только вкусную еду |
| старик | жениться чаще |
| ломать голову | исполнить завещание |
| построить дом | жить, занимаясь делом |

**2 Ответьте на вопросы.**

- Картның ничә улы булган?
- Картның олы улына әйткән васыятен табып укыгыз.
- Уртанчы улына әтиләре нәрсә дип әйтеп калдырган?
- Әтисенең кече улына әйткән васыятен укыгыз.
- Әтиләре улларын ничек көн итәргә өндәгән?

**3 Расположите толкование пунктов завещания отца сыновьям в правильном порядке и соедините их с соответствующими цифрами.**

| | |
|---|---|
| А) «авыл саен йорт сал» | 1. «эшләп ашасаң, кара икмәк тә бик тәмле булыр» |
| Б) «тәмле ашлар ашап кына яшә» | 2. «авыл саен дус-иш булдыр, дөньяда дуслар белән яшәве җиңелрәк була» |
| В) «ешрак өйлән» | 3. «эш артыннан йөреп, хатыныңны сагыныбрак кайтсаң, көн дә өйләнгән кебек булыр» |

**4 Расставьте буквы в правильном порядке, чтобы восстановить слово, значение которого дано рядом.**

ВЫТСЬАЯ — картның үләр алдыннан улларына әйтеп калдырган теләге, үтенече.

**5 Откройте скобки и поставьте глаголы в форму настоящего времени.**

Көннәрдән бер көнне боларга бер карт килеп (керү). Исәнлек-саулык (сорашу), тормышлары белән (кызыксыну) бу боларның.

**6 Найдите в тексте главное наставление отца, перепишите предложение на татарском языке. Переведите на русский язык.**

___

___

___

**7 Прочитайте пересказ и проверьте, правильно ли вы поняли содержание сказки.**

ЗАВЕЩАНИЕ

Жил-был отец, и было у него три сына. Перед смертью он завещал старшему строить дома в каждой деревне, среднему — есть только вкусную еду, а младшему — чаще жениться. После смерти отца сыновья задумались, как исполнить его волю.

Однажды к ним зашел старик и, выслушав их рассказы о завещании, объяснил, что отец имел в виду совсем другое: строить дома в каждой деревне — значит, заводить друзей в каждой деревне, потому что с друзьями жить легче; есть только вкусную еду — значит, зарабатывать на жизнь трудом, тогда и простой хлеб будет вкусным; а жениться чаще — значит, скучать по жене после работы, тогда каждый день будет как свадебный. Старик заключил, что отец призывал их трудиться.

Тогда сыновья стали исполнять волю отца так, как объяснил старик.

# Зирәк карт

Элек заманда буладыр бер патша. Ул җитмеш яшькә җиткән кешеләрне, барыбер эшкә ярамыйлар дип, үтертә торган була. Бер егетнең була җитмеш яшьлек атасы. Бу егет, атасын үтертәсе килмичә, аны байтак вакытлар яшереп асрый.

Егет, урамнан йөреп кайткан саен, атасы янына керә икән. Атасы моннан сорый:

— Нихәл, улым, дөньяда ниләр бар? — ди.

Егет күргәнен-ишеткәнен барын да сөйләп бирә икән.

Шулай беркөнне егет кайта, кайта да әтисе янына керә.

— Нәрсәләр күрдең, улым, ниләр ишеттең? — ди әтисе.

— Әти, — ди егет, — патша үзенең вәзирләре белән су буена төшкән, — ди. — Су төбендә яп-якты ялтырап торган гәүһәр күренә икән. Шуны су төбенә төшеп эзлиләр — юк, менгәч карыйлар, тагын су төбендә ялт итеп тора, — ди. — Шуларга бик аптыраганнар. Патшаның вәзирләре дә моның хикмәтен белми икән, — ди.

Карт әйтә:

— Әй, улым, — ди, — анда берәр агач бармы, су буенда? — ди.

— Нәкъ шул агач тирәсендә эзлиләр, — ди егет.

— Ул агач башында кош оясы бармы? — ди карт.